# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Корноухово авыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы торак пунктында

2024 елның 15 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Корноухово авыл җирлеге составына керүче Корноухово авылы торак пунктында гражданнар җыены Карар кылды:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово, Шетнево-Черемышево, Зюзино һәм Наумово авыллары торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан , өлешчә мобилизациягә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган һәм контракт буенча СВО зонасында хезмәт иткән мобилизацияләнгән гражданнар  тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;
- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- урамнарны яктырту җайланмасын төзекләндерү,яктырткычлар белән тәэмин иту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

3.Әлеге карарны Корноухово авыл җирлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шетнево-Черемышево авылы, Совет урамы, 21 йорт. Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зюзино авылы, Үзәк ур., 6А йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,Наумово авылы, Наумово урамы, 3 нче йорт һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта: http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. 4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г. С. Гумашян

Корноухово авыл җирлеге башлыгы Г. С. Гумашян